**РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН**
**РУКОВОДИТЕЛЬ**
**ИСПОЛНИТЕЛЬНОГО**
**КОМИТЕТА**
ЧЕРЕМШАНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
ЧИРМЕШӘН МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОНЫ
**БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**
**ҖИТӘКЧЕСЕ**

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

08 ноябрь 2019 ел **Чирмешән авылы** № 460

2020 - 2022 елларга Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районында экологик хәлне тәэмин итүне яхшырту буенча әйләнә-тирә мохитне саклау һәм табигый ресурслардан һәм табигать саклау чараларыннан рациональ файдалану Программасын раслау турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, «Әйләнә-тирә мохитне саклау турында» 2002 елның 10 гыйнварындагы 7-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә Чирмешән муниципаль районы Башкарма комитеты **КАРАР БИРӘ:**

1.«2020 - 2022 елларга Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районында экологик хәлне тәэмин итүне яхшырту буенча әйләнә-тирә мохитне саклау һәм табигый ресурслардан һәм табигать саклау чараларыннан рациональ файдалану» программасын раслэрга (1нче кушымта).

2.Чирмешән муниципаль районының Финанс-бюджет палатасына ел саен Чирмешән муниципаль районы бюджетын чираттагы финанс елына һәм план чорына формалаштырганда Программа чараларын тормышка ашыруга акчаны хәстәрләп куерга тәкъдим итәргә.

3. Әлеге карарны хокукый порталда (pravo.tatarstan.ru) һәм Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районының рәсми сайтында интернет челтәрендә урнаштырырга.

4. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Чирмешән муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең беренче урынбасары Кәримов И.И. йөкләргә.

Башкарма комитет
Җитәкчесе И.Н.Шәйдуллин

Татарстан Республикасы
Чирмешән муниципаль районы
Башкарма комитеты җитәкчесенең
2019 елның 8 ноябрендәге
460 номерлы карарына
1 нче кушымта

**«2020-2022 елларга Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районында экологик хәлне тәэмин итүне яхшырту буенча әйләнә-тирәлекне саклау һәм табигый ресурслардан һәм табигать саклау чараларыннан рациональ файдалану»**
**Программасы**

ПРОГРАММА ПАСПОРТЫ

| | |
|---|---|
| Программаның исеме | «Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районында 2020-2022 елларга экологик хәлне тәэмин итүне яхшырту буенча әйләнә-тирә мохитне саклау һәм табигый ресурслардан һәм табигать саклау чараларыннан рациональ файдалану (алга таба-Программа) |
| Программаны эшләү турында нигез | «Әйләнә-тирә мохитне саклау турында» 2002 елның 10 январендәге 7-ФЗ номерлы Федераль закон |
| Программаның заказчысы һәм Программаны әзерләүче | Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы Башкарма комитеты |
| Программаның максатлары | Чирмешән муниципаль районында экологик куркынычсызлык дәрәҗәсен күтәрү |
| Программаның бурычлары | -икътисадның экологик нәтиҗәлелеген күтәрү нигезендә әйләнә - тирәлеккә антропоген йөкләнешне киметү;<br>-Чирмешән муниципаль районы территориясенең биологик төрлелеген саклау һәм торгызу;<br>-әйләнә-тирә мохитне күзәтү һәм гидрометеорология системасы эшчәнлегенең нәтиҗәлелеген күтәрү; |
| Программаны тормышка ашыру сроклары | 2020-2022 еллар |
| Программаны финанслау күләме һәм чыганаклары | 2020-2022 еллар<br>Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районының җирле бюджеты |

| | |
|---|---|
| Программаны тормышка ашыруның көтелгән ахыргы нәтиҗәләре | Барлыгы 2020-2022 елларда Программа чараларын үтәүгә 6097,5 мең сум күләмендә финанс чыгымнары планлаштырыла:<br>2020ел – 2032,5мең сум;<br>2021ел - 2032,5мең сум;<br>2022ел - 2032,5 мең сум.<br>Бюджеттан бүлеп бирелә торган акчалар күләме фаразланган характерга ия һәм программа чаралары исемлеген, аларны гамәлгә ашыру срокларын һәм этапларын төгәлләштерүне исәпкә алып, тиешле финанс елына бюджет проектын формалаштырганда, ирешелгән нәтиҗәләр нигезендә, ел саен билгеләнгән тәртиптә корректировкаланырга тиеш. |
| Программаны тормышка ашыруның көтелгән ахыргы нәтиҗәләре һәм социаль-икътисадый нәтиҗәлелек күрсәткечләре | Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районында гомуми экологик хәлне яхшырту.<br>Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы укучыларының, халкының экологик культурасын һәм экологик аңын арттыру һәм пропагандалау.<br>Табигатьне яклау һәм саклауда кызыксыну дәрәҗәсен күтәрү. |